**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Административный регламент предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Предоставление в границах земель лесного фонда лесных участков в аренду без проведения торгов»**

В связи с внесением изменений в нормативные правовые акты, регулирующие лесные отношения, **постановляю**:

1. Внести в Административный регламент предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Предоставление в границах земель лесного фонда лесных участков в аренду без проведения торгов», утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 26 декабря 2013 года № УП-1277 «Об утверждении Административного регламента предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Предоставление в границах земель лесного фонда лесных участков в аренду без проведения торгов» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 15 января 2016 года № УП-6, от 8 октября 2016 года № УП-911, от 27 июля 2017 года № УП-660, от 11 января 2019 года № УП-4, от 27 октября 2021 года № УП-828 и Указом Раиса Республики Татарстан от 12 апреля 2023 года № 231), следующие изменения:

а) в пункте 2.9:

абзац пятый изложить в следующей редакции:

«сведения о наличии правоустанавливающих или правоудостоверяющих документов на объекты, подлежащие реконструкции, эксплуатации (при предоставлении лесных участков для реконструкции, эксплуатации линейных объектов, гидротехнических сооружений);»;

в абзаце седьмом слова «проекта в области освоения лесов» заменить словами «проекта в целях развития лесного комплекса», слова «проектов в области освоения лесов» заменить словами «проектов в целях развития лесного комплекса»;

б) в пункте 2.10:

абзац второй подпункта 2 изложить в следующей редакции:

«сведения о наличии правоустанавливающих или правоудостоверяющих документов на объекты, подлежащие реконструкции, эксплуатации (при предоставлении лесных участков для реконструкции, эксплуатации

линейных объектов, гидротехнических сооружений);»;

в абзаце втором подпункта 4 слова «проекта в области освоения лесов» заменить словами «проекта в целях развития лесного комплекса», слова «проектов в области освоения лесов» заменить словами «проектов в целях развития лесного комплекса»;

в) пункт 3.11 изложить в следующей редакции:

«3.11. Основанием для начала административной процедуры (действия) является получение специалистом Отдела зарегистрированного заявления и документов о предоставлении лесного участка в аренду, а также документов (сведений), полученных от органов государственной власти и организаций, указанных в пункте 2.10 настоящего Административного регламента, – при предоставлении лесного участка в аренду для строительства водохранилищ и иных искусственных водных объектов, создания и расширения территорий речных портов, строительства гидротехнических сооружений.»;

г) пункт 3.18 изложить в следующей редакции:

«3.18. Основанием для начала административной процедуры (действия) является получение специалистом Отдела зарегистрированного заявления и документов о предоставлении лесного участка в аренду, а также документов (сведений), полученных от органов государственной власти и организаций, указанных в пункте 2.10 настоящего Административного регламента, – при предоставлении лесного участка в аренду в целях осуществления геологического изучения недр, разведки и добычи полезных ископаемых, рыболовства, строительства, реконструкции, эксплуатации линейных объектов, реализации приоритетных инвестиционных проектов в целях развития лесного комплекса, заготовки древесины на лесных участках, предоставленных юридическим лицам или индивидуальным предпринимателям для использования лесов в соответствии со статьями 43–46 Лесного кодекса Российской Федерации, эксплуатации водохранилищ и иных искусственных водных объектов, реконструкции и эксплуатации гидротехнических сооружений, при предоставлении лесного участка в аренду юридическим лицам, индивидуальным предпринимателям для осуществления видов деятельности в сфере охотничьего хозяйства, а также при предоставлении лесного участка в аренду собственнику находящихся на таком лесном участке здания, сооружения (помещения в таком здании, сооружении) или юридическому лицу, которому эти объекты предоставлены на праве хозяйственного ведения или оперативного управления.».

2. Настоящий Указ вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
21 июля 2023 года
№ 502

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Урман мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 26 декабрендәге ПУ-1277 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 15 гыйнварындагы ПУ-6 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2017 елның 27 июлендәге ПУ-660 номерлы, 2019 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы, 2021 елның 27 октябрендәге ПУ-828 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 12 апрелендәге 231 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Урман министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.9 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«реконструкцияләнергә, эксплуатацияләнергә тиешле объектларга (урман кишәрлекләрен линия объектларын, гидротехник корылмаларны реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен биргәндә) хокукларны билгели яисә хокукларны раслый торган документларның булуы турында белешмәләр;»;

җиденче абзацта «урманнарны үзләштерү өлкәсендә проектның» сүзләрен «урман комплексын үстерү максатларында проектның» сүзләренә, «урманнарны үзләштерү өлкәсендә проектларның» сүзләрен «урман комплексын үстерү максатларында проектларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2.10 пунктта:

2 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«реконструкцияләнергә, эксплуатацияләнергә тиешле объектларга (урман кишәрлекләрен линия объектларын, гидротехник корылмаларны

реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен биргәндә) хокукларны билгели яисә хокукларны раслый торган документларның булуы турында белешмәләр;»;

4 пунктчаның икенче абзацында «урманнарны үзләштерү өлкәсендә проектның» сүзләрен «урман комплексын үстерү максатларында проектның» сүзләренә, «урманнарны үзләштерү өлкәсендә проектларның» сүзләрен «урман комплексын үстерү максатларында проектларның» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары төзү, елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү өчен урман кишәрлеген арендага биргәндә – Бүлек белгеченең урман кишәрлеген арендага бирү турында теркәлгән гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында күрсәтелгән документларны, шулай ук дәүләт хакимияте органнарыннан һәм оешмалардан килгән документларны (мәгълүматларны) алуы административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез була.»;

г) 3.18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.18. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны тикшерү һәм чыгару, балыкчылык, линия объектларын төзү, ресконструкцияләү, эксплуатацияләү, урман комплексын үстерү максатларында өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Урман кодексының 43–46 статьялары нигезендә урманнардан файдалану өчен юридик затларга яисә шәхси эшкуарларга бирелә торган урман кишәрлекләрендә агач әзерләү, сусаклагычларны һәм ясалма су объектларын эксплуатацияләү, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкарганда юридик затларга, шәхси эшкуарларга урман кишәрлекләрен биргәндә, шулай ук милекчегә урман кишәрлеген арендага биргәндә, мондый урман кишәрлегендәге биналар, корылмалар (мондый бинадагы бүлмәләр, корылмалар) яисә мондый объектлар хуҗалык итү яисә оператив идарә хокукы белән бирелгән юридик затка бирелгәндә – Бүлек белгеченең урман кишәрлеген арендага бирү турында теркәлгән гаризаны һәм әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында күрсәтелгән документларны, шулай ук дәүләт хакимияте органнарыннан һәм оешмалардан килгән документларны (мәгълүматларны) алуы административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез була.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 502